Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
детский сад «Миляуша» села Терси
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Принято
на педагогическом совете
Протокол № 1 от 29.08 2023 года

Утверждено
заведующий МБДОУ
д/сад «Миляуша» с.Терси
Г.Г.Ягьфарова
«29» 08 2023 г
Приказ № 4 «О» от 29.08 2023 г

# Рабочая программа
## воспитателя по обучению детей татарскому (родному) языку
## на 2023-2024 учебный год.

Автор составитель:
Шайхиева Г.М.

с.Терси
2023 г

Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
детский сад «Миляуша» села Терси
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Принято
на педагогическом совете
Протокол № ____ от_______ 2023 года

Утверждено
заведующий МБДОУ
д/сад «Миляуша» с.Терси
Г.Г.Ягьфарова _________
«____» ___________ 2023 г
Приказ № «О» от _____ 2023 г

# Рабочая программа
# воспитателя по обучению детей татарскому (родному) языку
# на 2023-2024 учебный год.

Автор составитель:
Шайхиева Г.М.

с.Терси
2023 г

**Эчтәлек**

1. Максатлар бүлеге....................................................................................................................................3
1.1. Аңлатма язуы..........................................................................................................................................3
Эш программасының максаты һәм бурычлары...................................................................................4
1.2. Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр.......................................................5

2. Эчтәлек бүлеге........................................................................................................................................6
2.1. Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге эчтәлеге.................................................................6
2.2. Эш төрләре һәм формалары.................................................................................................................9
2.3. Еллык комплекслы – тематик планы..................................................................................................10
2.4. Ата- аналар белән эш.............................................................................................................................39

3. Оештыру бүлеге.......................................................................................................................................40
3.1. Материаль - техник тәэмин ителү........................................................................................................40
3.2. Программа һәм методик тәэмин ителү................................................................................................41
3.3. Үстерешле әйләнә-тирә.............................................................................................................................41

Кушымта.......................................................................................................................................................43
1. Кулланылган әдәбият исемлеге..............................................................................................................43
2. Мониторинг...............................................................................................................................................43

## 1. Максатлар бүлеге

### 1.1. Аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре. Әлеге проблемаларның бер өлеше “Туган телдә сөйләшәбез” өйрәтү-методик комплектлары ярдәмендә чишелә. Тәкъдим ителгән әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Аның төп максаты ана телендә балаларның дөрес һәм яхшы телдән сөйләмен формалаштыру. Кече яшьтән үк баланың сөйләмен үстерү аның аралашу, танып белү, әхлакый һәм рухи юнәлешләр нигезен билгели.

Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. “Туган телдә сөйләшәбез” дип исемләнгән методик комплект икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына.

Методик әсбапта танып белү, коммуникация, матур әдәбият белән таныштыру кебек өч белем бирү өлкәсе карала. Нәниләр эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар - “Балалар бакчасы”, “Көз”, “Мин дөньяның бер кешесе”, “Минем әйләнә-тирәм”, “Кыш”, “Яңа ел бәйрәме”, “Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр”, “Халык иҗаты”, “Яз”, “Җәй”. Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә.

## **Эш программасының максаты һәм бурычлары**

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү мәсьәләләрен чишкәндә, өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла.

“Минем бакчам”, “Мин яратам сине Татарстан”, “Саулык –зур байлык,” “Исемең матур кемнәр куйган, ” “Кунак булсаң- тыйнак бул” “Исәнме мәктәп, ” “Кояш системасы,” “Дуслык белән көчле без һәм башка күп проектлар балалар тормышын чагылдыручы, үсемлек һәм тереклек дөньясына кагылышлы, экологик культура, табигатькә аңлы караш, туган җиргә, телгә мәхәббәт тәрбияләүгә булышлык итүче шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр; нәниләрдә кешелеклелек хисләре, үз-үзеңне тоту күнекмәләре, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләүгә, нәрсә – яхшы, нәрсә – начар, үзара дустанә мөнәсәбәтләргә, тормыш куркынычсызлыгы нигезләренә, юл хәвефсезлеге кагыйдәләренә, табигатьтә үз-үзеңне тоту күнекмәләренә кагылышлы эшчәнлекне үз эченә алган. Һәр эшчәнлектә халкыбызның тормыш сынавы аша узган тәрбия җәүһәрләре – мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар, табышмаклар, эндәшләр алынды. Ана телебезнең матурлыгы, камиллеге һәм байлыгы гәүдәләнгән әлеге энҗе-мәрҗәннәр балаларның сөйләмен баетуда, тапкырлык-зирәклекләрен тирәнәйтүдә, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерүдә ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз.

Бу укыту-методик комплектында ФГОС күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:

-“Танып белү ” белем биру өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләрдә экология бурычларын гамәлгә ашыруны, туган як, өлкәннәр хезмәте турында балаларның белемнәрен тирәнәйтүне максат итеп куя. Шушы максатларны тормышка ашыруга ярдәм итүче зурлар төркемендә 30 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 35 эшчәнлек каралган. Балалар белән эшчәнлек сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла.

- “Аралашу” белем бирү өлкәсе нәниләрдә туган телгә мәхәббәт, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруга, сабыйларга кара- каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу белем бирү өлкәсенә туры килгән, зурлар төркемендә 36 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек тәркемендә 38 эшчәнлек тәкъдим ителә. Авазларны кабатлау, калын һәм нечкә авазларның дифференцациясе һәр эшчәнлеккә өлеш итеп кертелде .Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, сәхнәләштерү, өстәл театры карау, рәсемнәр, картиналар карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар; тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота.

- “Матур әдәбият” белем бирү өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өндәүче, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирүче, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтүче, яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләрбелән танышуны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя. Бу белем бирү өлкәсе зурлар төркемендә 31 эшчәнлекне, мәктәпкә әзерлек төркемендә 30 эшчәнлекне үз эченә ала. Эшчәнлек матур әдәбият әсәрләрен уку, эчтәлеген сөйләү, ятлау кебек эш формалары кулланып оештырыла..

Тәкъдим ителә торган программа түбәндәге эш төрләрен һәм бурычларын үз өстенә ала:

1. Сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру.
2. Авазларны ишетә һәм аера белергә,шулай ук татар теле өчен генә хас булган авазларны дөрес әйтергә өйрәтү.
3. Грамматик күнекмәләр формалаштыру.
4. Җөмләләрне дөрес төзергә өйрәтү.

5. Бәйләнешле сөйләм күнекмәләре булдыру.
6. Татар балалар әдәбияты һәм фольклоры үрнәкләре белән таныштыру.
7. Татар халык мәдәнияте турында төшенчә бирү.

## 1.2. Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр

### Уртанчылар төркеме:

*Балаларның тормыш тәҗрибәсендә очрамаган предметлар һәм күренешләрне белдерүче сүзләр исәбенә сүзлек запасын арттыру.
*Эмоциональ халәтне (ачулы, моңсу), этик сыйфатларны (хәйләкәр, юмарт), предметларның билгеләрен һәм үзенчәлекләрен белдеүче сүзләрне активкулланышка кертү. Антонимнарны сөйләмдә аңлап куллану; сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа сүз ясалу очракларын белү (тәм-тәмле, бакча-бакчачы, тоз-тозсыз һ.б.).
*Авазларны дөрес әйтү өстендә аңлап эшләү, сүздә беренче авазны аерып әйтә белү.
*Сюжетлы рәсемнәрнең эчтәлеге турында тулы, мәгънәле итеп сөйли белү; исем, өлкәннәр ярдәмендә, уенчыкны тасвирлап сөйләү үрнәкләрен кабатлау, таныш әсәрләрдән өзекләрне сәхнәләштереп сөйләү.
*Үз эшчәнлеген (уеда, көнкүрештә һәм башка эш-гамәлләрдә) актив сөйләм белән бергә алып бару.

### Зурлар төркеме:

*Уен кагыйдәләрен аңлату; яшьтәшләренең җавапларын, әйткән фикерләрен дусларча һәм дәлилләр китереп бәяләү.
*Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллану; туры һәм кыек сөйләмнән файдалану.
*Үз тәҗрибәсеннән чыгып, сюжетлы рәсемнәр, картиналар тупламасы буенча мөстәкыйль рәвештә хикәяләр төзү; әкиятләрнең ахырларын тәмамлау; зурбулмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү.
*Сүздә авазның урынын билгели белү.
*Исемне берничә сыйфат белән алыштыра белү; сүзне охшаш мәгънәле сүз белән алыштыра белү.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме:

*Күмәк сөйләшүдә катнашу: сораулар бирә һәм сорауларга ашыкмыйча җавап (фикереңне дәлилләп) кайтару белү; вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле, аңлаешлы итеп сөйләү.
*Әдәпле әңгәмәдәш булу: тавышны күтәрмичә, тыныч итеп сөйләшү.
*Өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашканда сөйләм әдәбе кагыйдәләрен яхшы белү.
*Сөйләмдә синонимнар, антонимнар, кушма җөмләләр куллану.
*"Аваз", "иҗек", "сүз", "җөмлә" төшенчәләрен аерып әйтә белү. Җөмләдә башта сүзләрне, ә аннары сүздәге авазларны, иҗекләрне әйтү. Җөмләдә бирелгән аваз кергән сүзләр эзләп табу, сүздә авазның урынын билгеләү.
*Зур булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү, сәхнәләштерү; алдан төзелгән план һәм тәрбияче үрнәге буенча үз тәҗрибәңнән чыгып предметлар, сюжетлы рәсемнәр җыелмасы буенча сөйли белү.

## 2. Эчтәлек бүлеге

## 2.1. Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

План балалар бакчасында балалар белән эшләү өчен ФДББС, Р.К. Шаеховаың "Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы", Ф.В Хәзрәтованың "Туган телдә сөйләшәбез" укыту –методик кулланмасы нигезендә балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү, тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау, телне тоемлау сәләте булдыру максатыннан чыгып төзелде. Методик әсбап танып белү, сөйләм үстерү, матур әдәбият белән таныштыру кебек белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар — «Безнең балалар бакчасы», «Көз», «Мин — дөньяның бер кешесе», «Минем әйләнә-тирәм», «Кыш», «Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр», «Халык иҗаты», «Яз», «Җәй».

Методик кулланмада ФДББС буенча өч белем бирү өлкәсе: танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомум кабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала. Дүртенче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Шундый формаларның берсе булып бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып үткәрелә. Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалаштыруга: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомум кабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә.

План ел дәверендә «Җәй белән саубуллашу», «Көз», «Мин һәм минем гаиләм», «Минем йортым, минем шәһәрем», «Кыш», «Ватанны саклаучылар көне», «Сигезенче март», «Халык җәүһәрләре», «Яз», «Җәй» кебек темалар үзләштерүне күздә тота.

## Балаларның үсешенең яшь үзенчәлекләре

Уртанчылар төркеме 4–5 яшькә кадәр. Уртанчы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгәндә рольдән үзләрен аера башлыйлар. Уен процессында рольләр үзгәрергә мөмкин. Алар үзләре өчен түгел, ә уен мәгънәле итү өчен уйный башлыйлар. Уендагы һәм чынбарлыктагы мөнәсәбәтләр аерымлана. Сүрәтләү эшчәнлеге шактый үсеш ала. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән форма ала. Кешенең график сүрәте гәүдә, күз, авыз, борын, чәч, кайвакыт кием һәм аның детальләре булу белән харкатерлана. Сүрәтләү эшчәнлегенң техник ягы камилләшә. Балалар төп геометрик фигураларны ясый, кайчы белән кисә, сүрәтләрне кәгазьгә ябыштыра алалар һ.б. Конструкцияләү катлаулана. 5-6 детальдән торган корылмалар барлыкка килә. Уйлап чыгарып конструкцияләү, шулай ук төзү эзлеклеген планлаштыру күнекмәләре формалаша. Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак һәм эре моториканың уңай үзгәрешләре белән характерлана. Җитезлек, хәрәкәт координациясе үсә. Кечкенәләр белән чагыштырганда балалар бу

яшьтә тигезлекне яхшы саклыйлар, зур булмаган тоткарлыкларны атлап чыгаралар. Туп белән күнегүләр катлаулана. Зиһенгә алу сәләте күбрәк үсеш ала. Балалар теге яки бу предметка охшашган форманы атый беләләр. Алар катлаулы объектларда гади формаларны аерып күрсәтә һәм гади формалардан катлаулы объектлар барлыкка китерә алалар. Балалар предмет төркемнәрен сенсорик билгеләре – зурлыгы, төсе буенча тәртипкә салырга, биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле. Хәтер күләме үсә. Балалар 7-8 предметның исемен истә калдыра алалар. Истә калдыру мөмкинлекләре үсә. Алар олылар тапшырган эшне истә калдралар, кечкенә шигырьләрне ятлый алалар һ.б. Тасвирлы фикерләү сәләте үсә башлый. Балалар катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишүдән гади схемалаштырыган сүрәтләр кулланалар. Алар схема буенча төзи, лабиринтлы мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күрә белү сәләте үсә. Объектларның пространствода урнашулары нигезендә. Балалар аларның үзара йогынты ясашуы нәтиҗәсндә нәрсә килеп чыгасын әйтә алалар. Тик аларга читтән күзәтүче позициясенә басу һәм образларны күзаллап үзгәртү әлегә авыр. Күз алдына китерү, уйлап чыгару (воображение) сәләте үсә. Оригинальлек һәм ирекле булу кебек сыйфатлар формалаша. Балалар мөстәкыйль рәвештә бирелгән темага зур булмаган әкият уйлап чыгара алалар. Игътибарлык сәләте үсә. Бала 15-20 минут дәвамында игътибарын туплап эшли алырга сәләтле. Ул нинди дә булса эш эшләгәндә катлаулы булмаган шартны хәтерендә тотып тора ала. Авазлар әйтелеше һәм дикция яхшыра. Сөйләм балаларның активлыгын үстерә. Алар хайван тавышлары чыгаралар. Теге яки бу персонажның сөйләмен интонация белән аерып күрсәтә алалар. Сөйләмнең грамматик ягы үсеш ала. Балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыгалар. Бер-берсе белән аралашканда балаларның сөйләме ситуациягә бәйле, ә олылар белән аралашканда ситуациягә бәйләнмәгән була. Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Ул бала элләккән конкрет ситуациядән читкә тайпыла. Танып белү мотивы алга чыга. Аралашу процессында алган мәгълүматлар бик үк аңлашылып бетмәсәләр дә, балада кызыксыну уяталар. Бала өлкәннәрнең үзен ихтирам итүләрен тели, мактау сүзе аның өчен бик зур әһәмияткә ия була бара. Бу баланың артык үпкәләүчән булуына китерә. Шелтә, кисәтүләргә тискәре мөнәсәбәт туа. Артык үпкәләүчәнлек бу яшьнең феномены булып тора. Яшьтәшләре белән бала сайлап кына аралаша башлый. Ул кайбер иптәшләренә өстенлек бирә. Уен вакытында даими партнерлар барлыкка килә. Төркемдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышу барлыкка килә. Ярышу үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен әһәмиятле. Бу үз чиратында Мин образының үсешенә, аның детальләштерүенә китерә. Бу яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсү; рольле һәм 4 тормышчан үзара бәйләнешләр барлыкка килү; сүрәтләү эшчәнлеге үсү; үзең уйлап конструкцияләү; планлаштыру, зиһенгә алу сәләте камилләшү, образлы, хыялый фикерләү, танып белүдә мин-минлек (минеке генә дөрес дигән позиция); хәтер, игътибар, сөйләм, дәлилли белү сәләте үсү, олыларның хөрмәтенә ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, ярышу кебек сыйфатлар барлыкка килү, Мин образының үсүе белән характерлана.

5 яшьтән алып 6 яшькәчә балаларның яшь үзенчәлекләре. Бу яшьтәге балалар уен башыннан рольләрне бүлеп, шушы рольгә кереп уен ахырына кадәр уйный алалар. Уен барышында үзара мөнәсәбәт эчтәлеге буенча да, интонациясе буенча да рольгә туры килгән аралашу белән үрелеп бара. Балаларның чынлыкта аралашкан сөйләм теле, роль сөйләм теленнән аерылып тора. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне аңлый башлыйлар, кайсыдыр роль башкалар белән чагыштырганда алар өчен якынрак була. Рольләр бүлгәндә төрле конфликтлар чыгарга мөмкин. Уен тирәлеге оешканлыгы күзәтелә, “үзәк” һәм “периферия” аерылып чыга. Уеннарда балаларның эш гамәлләре күпкырлыга әйләнә. Балаларның сынлы сәнгать эшчәнлекләре үсә. Бу вакыт балаларның иң актив рәсем ясау чоры. Ел дәвамында балалар 2000 артыграк рәсем ясарга сәләтле. Эчтәлекләре буенча рәсемнәр бик төрле: китап һәм каралган фильмнарга иллюстрацияләр, көндәлек тәэсирләр, күзаллаган вакыйгалар. Гадәттә рәсемнәр төрле обьектларның схематик сурәтләрен чагылдыралар, ләкин композицияләренең оригинальлекләре белән аерылып торалар. Кеше рәсеме пропорциональрәк һәм була башлый. Рәсемгә карап кешенең җенесе һәм эмоциональ хәләте турында төгәл әйтеп була. Төсләрне, формаларны, зурлыкларны, предметлар төзелешен аңлап кабул итүләре камилләшә.

Алар төп төсләрне генә түгел, барлык төсләрне дә, овал, өчпочмак, турыпочмаклык формаларын да әйтә башлыйлар. Объектларның зурлыкларын кабул итәләр, 10 га кадәр төрле предметларны үсә бару һәм кими бару тәртибендә бик җиңел төзиләр. Шулай да балалар тирә - юньдәге объектларның торышын анализлаганда авырлыклар кичерәләр. Кабул итү балаларда төрле авырлыклар тудыра, бигрәк тә берьюлы берничә, шул ук вакытта капма-каршы билгеләрне исәпкә аласы булса. Образлы фикерләү мәктәпкәчә яшьтә үсүен дәвам итә. Балалар билгеләре буенча предметларны группаларга туплый алалар. Психологлар тикшеренүләреннән күрсәкәнчә, мәктәпкәчә өлкән төркем балаларының күз аллаулары оригиналь һәм эзлекле хикәяләр төзергә мөмкинлек бирә. Ләкин күзаллаулары аны үстерү өчен махсус эш алып барганда гына үсеш ала. Сөйләм үсеше дәвам итә, бигрәк тә аваз ягы. Балалар сызгырулы, сонор һәм чыжылдаучы авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Фонематик ишетү сәләте, сәнгатьле сөйләм теле көндәлек тормышта, сюжетлы рольле уеннарда үсә. Баланың аңга алуы катлаулы формалы объектларны анализлый алуыннан чыгып характерлана; гомумиләштерү, күз аллау, ирекле игътибар сәләте, сөйләме, “Мин” үсеш ала.
6-7 яшьтәге балалар уен башлаганчы балалар рольләрне бүлеше һәм эш-гамәлләрне яраклаштырып төзи беләләр. Уендагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара. Балаларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрдәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар. Уен тирәлеген оештырганда, мәгънәви яктан “үзәк” һәм “периферия” аерымлану күзәтелә. Бу яшьтә балаларның сынлы сәнгать белән кызыксынулары аеруча көчәя. Алар бик еш рәсем ясый башлыйлар. Балалар ел дәвамында 2 мең чамасы рәсем ясарга сәләтле. Рәсемнәр эчтәлекләре ягыннан бик күптөрле: аларда балаларның тормыштан алынган тәэсирләре дә, уйлап чыгарылган ситуацияләр дә, фильм һәм китапларга иллюстрацияләр дә чагылырга мөмкин. Рәсем сюжетлы характер ала, күп тапкыр кабатланучы аз гына яки җитди үзгәрешләре булган сюжетлар бик еш очрый. Кеше сүрәте детальләштерелгән һәм пропорциональрәк була бара. Рәсем буенча, сүрәтләнгән кешенең җенесе һәм эмоциональ хәле турында әйтеп була. Конструкцияләү бу эшчәнлек өчен шартларны анализлый белүләре белән характерлана. Балалар агач конструктор детальләрен кулланалар һәм атыйлар. Конструкцияләү эшчәнлеге схема нигезендә, үзләре уйлап яки шарт буенча эшкә ашырыла ала.
Балалар, берничә (2,4,6) тапкыр бөкләп, кәгазьдән, шулай ук табигый материаллардан конструкцияли алалар. Төсне , форма һәм зурлыкны,предметларның төзелешен аңлау,кабул итү камилләшә бара. Балаларның күзаллаулары системалаштырыла. Балалар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, ә арадаш төсләрнең төсмерләрен дә , шулай ук турыпочмак, овал, өчпочмакларның формаларын да аералар һәм атыйлар.Бер дистә предметны зурлыклары буенча рәткә тезеп куя алалар.
Бу яшьтә уйлап чыгару сәләте үсү балаларга шактый оригиналь һәм эзлекле киңәйтелгән хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Балаларның игътибар тотрыклылыгы үсә. Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә. Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Бу яшьнең казанышлары түбәндәгеләр белән характерлана:уен эшчәнлегендә рольләр бүешү;уен пространствосын төзи белү;югары нәтиҗәлеге белән аерылып торган рәсем эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне карап гомумиләштерә белү.Зиһенгә алу объектларның катлаулы формаларын анализлау белән характерлана;фикерләү чараларын(схемалы,комплекслы кузаллаулар,цикллы үзгәрешләр турында кузаллаулар)үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте үсә,гомумиләштерү күнекмәләре уйлап чыгару сәләте,тотрыклы игътибар, сөйләм,*Мин* образы үсә.
Укыту-методик комплекты ФДББС дә күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе: (“Сәламәтлек”, “Физик культура”, Социальләштерү”, “Хезмәт”, “Куркынычсызлык”, “Танып – белү”, “Аралашу”, “Матур әдәбият уку”, “Иҗат”, “Музыка”) буенча куелган бурычларны күздә тотып эшләнде. Һәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге стуктурасында интегральләштереп бирелде.

Укыту-методик комплектында тупланган материал балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, тирә - юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә кулланылыр һәм ныгытылыр дип өметләнәбез.

“Туган телдә сөйләшәбез” - балаларыбызга халкыбызның тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт-итәгать тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклаык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

## 2.2. Эш төрләре һәм формалары

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## Еллык комплекслы – тематик план
## Уртанчылар төркеме

| Темалар | Эшчәнлек төрләре | Максат хәм бурычлар | Эшчәнлек саны | Үткәрү вакыты | Йомгаклау өлеше |
|---|---|---|---|---|---|
| **Танып белү өлкәсе.**<br>**1. Белем бәйрәме.** | Без балалар бакчасында. | Балаларның хәтер сәләтен үстерү. | 1 | 4.09 | |
| | Безнең китаплар. | Китапка хөрмәт тәрбияләү. | 1 | 5.09 | |
| | Безнең яраткан апабыз. | Өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. | 1 | 8.09 | Бәйрәмдә катнашу |
| | Безнең уенчыклар. | Балаларның фикерләвен камилләштерү. | 2 | 11,12.09 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Ә.Хәсәновның “Балалар бакчасында” хикәясен уку. | Китапка кызыксыну формалаштыру. | 1 | 15.09 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Г.Лотфиның “Ул бакчаны ярата” шигырен уку. | Сорауларга җавап бирү осталыгын ныгыту. | 1 | 18.09 | |
| | Кабатлау. | Алда үтелгәннәрне кабатлау. | 2 | 19,22.09 | |
| | Басуга бару. | Яшелчәләр турында белемнәрен ныгыту. | 2 | 25,26.09 | |
| | Куян кучтәнәчләре. | Көз.көзге уңыш турында күзаллауларын үстерү. | 2 | 29,02.10 | “Сөмбелә” бәйрәме |
| **Танып белү өлкәсе.**<br>**2. Көз.** | Көзге яфраклар. Күгәрчен. | Балаларның күзәтүчәнлекләрен үстерү. | 1 | 03.10 | |
| | “Песи балалары белән” дигән сюжетлы картина карау һәм хикәя төзү. | Көзге үзгәрешләр турында белемнәрен ныгыту. | 1 | 06.10 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Сөйләм телен үстерү.** | Л.Леронның “Яфрак бәйрәме” шигырен уку. | Балаларның кабул итүләрен хәтерен үстерү. | 1 | 09.10 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Г.Гомәрнең “Аю Әппәс” әкиятен уку. | Әкиятнең эчтәлеген истә калдырыргa,сорауларга җавап бирергә булышу. | 1 | 10.10 | |
| | Кабатлау. | Алда үтелгәннәрне кабатлау. | 2 | 13,16.10 | |
| **Танып белү өлкәсе. 3.Мин дөньның бер кешесе.** | Әти, әни һәм мин. | Гаилә турында күзаллауларын ныгыту. | 1 | 17.10 | |
| | Мин һәм кешеләр. | Кешенең үсеше турында күзаллаулар бирү. | 1 | 20.10 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Мин-үзем өчен иң кадерле кеше. | Балаларның үзаңнарын үстерү. | 1 | 23.10 | Гаилә рәсемнәре карау |
| | Гаилә. | Гаилә кешеләренә карата хөрмәт тәрбияләү. | 2 | 24,27.10 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Б.Рәхмәтнең “Бакчага киләчәк” шигырен уку. Һөнәрләр турында сөйләшү. | Кабул итүләрен, бәйләнешле сөйләмне үстерү. | 1 | 30.10. | |
| | Кабатлау. | Алда үтелгәннәрне ныгыту. | 2 | 31,03.11 | |
| | Минем данлыклы шәхәрем. | Балаларны туган шәхәр белән таныштыру. | 1 | 06.11 | |
| **Танып белү өлкәсе. 4.Минем шәһәрем, минем ватаным.** | Минем туган илем-Рәсәй. | Туган ил, аның тарихы турында белемнәрен ныгыту. | 1 | 07.11 | |
| | Синең куркынычсызлыгың- | Куркынычсызлык кагыйдәләре белән | 1 | 10.11 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | синең кулларда. | таныштыру. | | | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Ә.Рәшитнең “Кояшлы ил” шигырен уку. | Татарста Республикасы турында белемнәрен ныгыту. | 1 | 13.11 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Кабатлау. | Алда үтелгәннәр өстендә эш. | 2 | 14,17.11 | |
| | Кар Кызы, Кар Бөртеге бездә кунакта. | Балаларның хәтерен, диалоглы сөйләмен үстерү. | 1 | 20.11 | Яңа ел бәйрәме |
| **Танып белү өлкәсе.** **5.Яңа ел бәйрәме**. | Яңа ел уенчыклары. | Чыршы уенчыклары белән таныштыру. | 1 | 21.11 | |
| | Яңа ел килә. | Яңа ел бәйрәме турында белемнәрен формалаштыруны дәвам итү. | 1 | 24.11 | |
| | Киемнең үткәне һәм бүгенгесе. | Балаларда зәвык тәрбияләү. | 1 | 27.11 | |
| | Хуш киләсең, карлы кыш. | Сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү. | 1 | 28.11 | |
| | Миләш һәм балан җиләкләре. | Танып белүгә кызыксыну үстерү. | 1 | 01.12 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Кыш бабай турында хикәя төзү. | Күмәк хикәя төзү күнекмәләре формалаштыру. | 1 | 04.12 | Кыш турында хикәяләр уку |
| | Әкияти җәнлекләрнең кышкы маҗаралары. | Күмәк эшләү осталыгын үстерү. | 1 | 05.12 | |
| | Чыршыкай-купшыкай. | Күтәренке кәеф атмосферасын тудыру. | 1 | 08.12 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Хәйдәрнең “Керпе туны” әкиятен уку. | Кабул итүне, әкияткә уңай караш тәрбияләү. | 1 | 11.12 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | М.Фәйзуллинаның “Кыш бабай” шигырен ятлау. | Балаларның сүзлек запасын, хәтерен үстерү. | 1 | 12.12 | |
| | Ә.Кариның “Кыш”шигырен уку. | Яңа елга кызыксыну тәрбияләү. | 1 | 15.12 | |
| | Кабатлау. | Үткәннәргә йомгак ясау | 2 | 18,19.12 | |
| | Кыш билгеләре. | Кыш турында белемнәрен ныгыту. | 1 | 22.12 | Эчтәлекле рәсемнәр өстендә эш |
| **Танып белү өлкәсе. 6. Кыш.** | Кар бабай. | Балаларда эстетик хисләр тәрбияләү. | 1 | 25.12 | |
| | Җәнлекләр кышка әзерләнә. | Грамматик яктан дөркс сөйләм үстерү. | 1 | 26.12 | |
| | Җәнлекләр кышкы урманда. | Кыргый хайваннар турында күзаллауларын формалаштыру. | 1 | 29.12 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Ап-ак тунлы кыш. | Кыш турында белемнәрен тирәнәйтү. | 1 | 08.01 | |
| | Кыргый хайваннар. | Сөйләмнең грамматик төзелешен үстерү. | 1 | 09.01 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Хәйдәрнең “Керпе туны” әкиятенең эчтәлеген сөйләү. | Кайгыртучанлык,ярдәмләшү хисләре тәрбияләү. | 1 | 12.01 | |
| | Кабатлау. | Үткәннәргә йомгак. | 2 | 15,16.01 | |
| | Без-солдатлар. | Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру. | 1 | 19.01 | |
| **Танып белү өлкәсе. 7.Ватанны саклаучылар көне.** | Безнең Армия. | “Ватанны саклаучылар” төшенчәсен ачыклау. | 1 | 22.01 | Әтиләр көне |
| | Бакчабызның балта остасы. | Олылар хезмәте белән таныштыру,хөрмәт тәрбияләү. | 1 | 23.01 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Хәрби хөнәрләр. | Хәрби хөнәрләр,аларның төрләре белән таныштыру. | 1 | 26.01 | |
| | Очучылар. | Төрле гаскәр төрләренә, очучы хөнәренә карата патриотик хисләр тәрбияләү. | 1 | 29.01 | |
| | Иң яхшы әти. | Үз гаиләң, әти-әниең белән горурлану хисләре тәрбияләү. | 1 | 30.01 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | К.Булатованың “Солдатлар” дигән шигырен уку. | Солдатларга карата хөрмәт, патриотик хисләр тәрбияләү. | 1 | 02.02 | |
| | Кабатлау. | Үткәннәрне кабатлау. | 2 | 05,06.02 | |
| **Танып белү өлкәсе.**<br>**8.8 Март.** | Музыка җитәкчесендә кунакта. | Музыка җитәкчесенеңербөтен образын тудыру. | 1 | 09.02 | Әниләр бәйрәме |
| | Әнием турында сөйлим. | Әниләр турында тасвирлама төзү осталыгын формалаштыру. | 1 | 12.02 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Әниләр бәйрәме. | Әниләргә карата мәхәббәт, аларга карата ярдәм итү теләге тәрбияләү. | 1 | 13.02 | |
| | “Эт көчекләре белән” дигән картина буенча хикәя төзү. | Йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык үстерү. | 1 | 16.02 | |
| **Матур әдибият белән таныштыру өлкәсе.** | Д.Хәбибуллинаның “Бүләк” шигырен уку. | Балаларның хатын-кызлар бәйрәме турында белемнәрен тирәнәйтү. | 1 | 19.02 | Картина буенча эш |
| | Кабатлау. | Үткәннәрне кабатлау. | 2 | 20,26.02 | |
| **Танып белү өлкәсе.**<br>**9. Халык** | Савыт-саба. | Татар авылы күренеше белән таныштыру, савыт-саба турында белемнәрен тирәнәйтү. | 1 | 27.02 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **җәүһәрләре.** | Бияләй хәм перчатка. | Татар халкының кул эшләре белән таныштыру. | 1 | 01.03 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | | | | | |
| | Без әкият яратабыз. | Әкиятләр белән таныштыруны дәвам итү. | 2 | 04,05,03. | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Кабатлау. | Алда үтелгәннәрне ныгыту. | 2 | 11,12.03 | |
| | Кар бабай язны эзли. | Ел фасыллары, кыш,яз билгеләре турында белемнәрен ныгыту. | 1 | 15.03 | |
| **Танып белү өлкәсе. 10.Яз.** | Яз бүләкләре. | Яз, аның билгеләре турында белемнәрен тирәнәйтү. | 1 | 18.03 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Яз килә,яз! | Балаларның яз, аның айлары, билгеләре турында белемнәрен ныгыту. | 1 | 19.03 | |
| | Аюның язгы маҗаралары. | Балаларны исем, сыйфат кулланып гади җөмлә төзергә өйрәтү. | 1 | 22.03 | Яз бәйрәме |
| | Урман күлендә. | Балаларда дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | 1 | 25.03 | |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | К.Ушинскийның “Хайваннар бәхәсе” әсәрен уку. | Сорауларга җавап бирү осталыгын ныгыту. | 1 | 26.03 | |
| | Кабатлау. | Үткәннәргә нәтиҗә. | 2 | 29,01.04 | Кыш турында хикәяләр уку |
| | Татарстан байрагы. | Татарстан байрагының төсләре турында белемнәрен ныгыту. | 1 | 02.04 | |
| **Танып белү өлкәсе. 11. Җиңү бәйрәме.** | Җиңү бәйрәме. | Балаларның Җиңү көне турында күзаллауларын формалаштыру. | 1 | 05.04 | |
| | 9 майны каршылап. | Ветераннарга карата хөрмәт, горурлык | 1 | 08.04 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | хисләре тәрбияләү. | | | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Транспорт. | Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү. | 2 | 09,12.04 | Рәсемнәр карау |
| **Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе.** | Ә.Рәшитнең “Кояшлы ил” дигән шигырен яттан өйрәнү. | Туган илгә патриотлык хисләре тәрбияләү. | 1 | 15.04 | |
| | . “Тавык, тычкан, көртлек” татар халык әкиятен сөйләү | Балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга булышу. | 1 | 16.04 | |
| | Чәчәкләр. | Чәчәкләрнең характерл билгеләре белән таныштыруны дәвам итү. | 2 | 19,22.04 | |
| **Танып белү өлкәсе.**<br>**12. Җәй.** | Үрдәк бәбкәсе бак-бакны тасвирлау. | Уенчыкны эзлекле тасвирлап, кечкенә хикәя төзергә ярдәм итү. | 1 | 23.04 | |
| **Сөйләм телен үстерү өлкәсе.** | Бөҗәкләр. | Бөҗәкләр турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. | 1 | 26.04 | |
| | Чәчәкле җәй. | Җәйге ел фасылына хас билгеләр белән таныштыруны дәвам итү. | 1 | 29.04 | Дидактик уеннар уйнау |
| **Матур әдәбит белән таныштыру өлкәсе.** | “Күбәләкләр ничек килеп чыккак?” Филиппин халык әкиятен уку. | Әкиятнең эчтәлеген кабул итәргә, аңларга өйрәтү. | 1 | 30.04 | |
| **Кабатлау.** | | Ел буена үтелгәннәрне кабатлау. | 9 | 03,06,07, 10,13,14, 17,20,21 май | |

## Зурлар төркеме

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Максат һәм бурычлар | Эшчәнлек саны | Үткәрү вакыты | Йогаклау өлеше |
|---|---|---|---|---|---|
